**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О научно-образовательном центре мирового уровня в Республике Татарстан»**

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 24 февраля 2020 года № УП-115 «О научно-образовательном центре мирового уровня в Республике Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 21 июля 2020 года № УП-431 и от 14 ноября 2020 года № УП-755) следующие изменения:

а) в пункте 2 слова «федеральных государственных образовательных организаций высшего образования» заменить словами «организаций, осуществляющих образовательную деятельность по образовательным программам высшего образования и дополнительным профессиональным программам,»;

б) пункты 3, 6 и 7 признать утратившими силу;

в) приложение № 1 признать утратившим силу;

г) Положение о Наблюдательном совете научно-образовательного центра мирового уровня в Республике Татарстан изложить в новой редакции согласно приложению № 1;

д) состав Наблюдательного совета научно-образовательного центра мирового уровня в Республике Татарстан изложить в новой редакции согласно приложению № 2.

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
10 ноября 2023 года
№ 775

Приложение № 1
к Указу Раиса
Республики Татарстан
от «10» ноября 2023 года
№ 775

**Положение**
**о Наблюдательном совете научно-образовательного центра мирового уровня в Республике Татарстан**

## 1. Общие положения

1.1. Наблюдательный совет научно-образовательного центра мирового уровня в Республике Татарстан (далее – Наблюдательный совет) является коллегиальным совещательным органом управления научно-образовательным центром мирового уровня в Республике Татарстан (далее – Центр).

1.2. В своей деятельности Наблюдательный совет руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными конституционными законами, федеральными законами, Правилами предоставления грантов в форме субсидий из федерального бюджета на оказание государственной поддержки научно-образовательных центров мирового уровня на основе интеграции образовательных организаций высшего образования и научных организаций и их кооперации с организациями, действующими в реальном секторе экономики, утвержденными постановлением Правительства Российской Федерации от 30 апреля 2019 года № 537 (далее – Правила), иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан, иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

1.3. Положение о Наблюдательном совете и состав Наблюдательного совета утверждаются Указом Раиса Республики Татарстан.

## 2. Основные задачи, функции и права Наблюдательного совета

2.1. Основными задачами Наблюдательного совета являются осуществление общего руководства деятельностью Центра и определение программы его деятельности.

2.2. Наблюдательный совет для решения возложенных на него основных задач осуществляет следующие функции:

утверждение программы деятельности Центра;

согласование предложений по внесению изменений в программу деятельности Центра и в состав участников Центра;

внесение изменений в программу деятельности Центра и в состав участников Центра (при необходимости) в случаях, предусмотренных пунктом 24 Правил, по согласованию с Министерством науки и высшего образования Российской Федерации, а в иных случаях по согласованию с Советом научно-образовательных центров мирового уровня;

ежегодный мониторинг реализации программы деятельности Центра и утверждение ежегодного отчета о результатах реализации программы деятельности Центра;

утверждение положения об Управляющем совете Центра и его состава, определение порядка формирования, задач и функций иных консультативных и совещательных органов Центра;

иные функции, предусмотренные программой деятельности Центра и Правилами.

2.3. Наблюдательный совет для осуществления возложенных на него основных задач и функций имеет право:

запрашивать у органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов государственной власти, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан, организаций необходимую информацию по вопросам, относящимся к компетенции Наблюдательного совета;

приглашать и заслушивать представителей органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан и организаций по вопросам, относящимся к компетенции Наблюдательного совета;

осуществлять взаимодействие с федеральными органами государственной власти, органами государственной власти других субъектов Российской Федерации, органами местного самоуправления муниципальных образований других субъектов Российской Федерации и организациями;

привлекать к работе Наблюдательного совета экспертов из числа научных работников, представителей территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, государственных органов Республики Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан, бизнес-сообщества, а также общественных и политических деятелей.

## 3. Организация деятельности Наблюдательного совета

3.1. Состав Наблюдательного совета формируется из числа представителей федеральных органов исполнительной власти, исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан, иных государственных органов Республики Татарстан, организаций, осуществляющих образовательную деятельность по образовательным программам высшего образования

и дополнительным профессиональным программам, научных организаций и организаций, действующих в реальном секторе экономики.

3.2. В состав Наблюдательного совета входят председатель Наблюдательного совета, заместители председателя Наблюдательного совета и члены Наблюдательного совета, осуществляющие свою деятельность на общественных началах.

3.3. Наблюдательный совет возглавляет председатель Наблюдательного совета – Раис Республики Татарстан.

3.4. Наблюдательный совет своим решением назначает секретаря Наблюдательного совета.

3.5. Организационно-техническое обеспечение деятельности Наблюдательного совета осуществляется государственным научным бюджетным учреждением «Академия наук Республики Татарстан».

3.6. Заседания Наблюдательного совета созываются секретарем Наблюдательного совета по поручению председателя Наблюдательного совета. Заседания Наблюдательного совета проводятся по мере необходимости, но не реже одного раза в год.

3.7. Заседания Наблюдательного совета проводятся в очной и заочной форме. Заседание Наблюдательного совета может проводиться с использованием систем видео-конференц-связи.

3.8. Заседание Наблюдательного совета считается правомочным, если на нем присутствуют не менее двух третей от общего числа членов Наблюдательного совета.

3.9. Повестка заседания Наблюдательного совета формируется с учетом предложений членов Наблюдательного совета.

3.10. Секретарь Наблюдательного совета не позднее 10 дней до даты проведения заседания Наблюдательного совета представляет председателю Наблюдательного совета проект повестки заседания Наблюдательного совета, документы и информационные материалы по вопросам повестки заседания.

3.11. Утвержденная председателем Наблюдательного совета повестка заседания Наблюдательного совета, а также документы и информационные материалы по вопросам повестки заседания не позднее пяти дней до даты проведения заседания рассылаются членам Наблюдательного совета.

3.12. В заседаниях Наблюдательного совета с правом совещательного голоса принимают участие приглашенные эксперты, а также члены Управляющего совета Центра.

3.13. Решения на заседании Наблюдательного совета принимаются большинством голосов его членов, присутствующих на заседании, путем открытого голосования. В случае равенства голосов решающим является голос председателя Наблюдательного совета.

3.14. Решение Наблюдательного совета может быть принято посредством заочного голосования путем проведения письменного опроса членов Наблюдательного совета.

Сообщение о проведении заочного голосования с приложением материалов по вопросу, вынесенному на голосование, не позднее пяти дней до даты подведения итогов заочного голосования направляется секретарем Наблюдательного совета членам Наблюдательного совета любым способом, обеспечивающим его получение (в том числе посредством почтовой, факсимильной связи и по электронной почте). В сообщении указывается дата истечения срока представления членом Наблюдательного совета своего мнения по рассматриваемому вопросу в письменной форме.

Обобщение поступивших в письменной форме мнений членов Наблюдательного совета и подведение итогов заочного голосования осуществляются секретарем Наблюдательного совета.

Решение Наблюдательного совета считается принятым, если не менее двух третей от общего числа членов Наблюдательного совета представили в установленный срок свое мнение в письменной форме.

Решение принимается большинством голосов от общего числа членов Наблюдательного совета, представивших мнение в письменной форме. В случае равенства голосов решающим является голос председателя Наблюдательного совета.

## 4. Порядок оформления решений Наблюдательного совета

4.1. Решения Наблюдательного совета, принятые на его заседании или по итогам заочного голосования, оформляются протоколом, который подписывается председателем Наблюдательного совета.

4.2. Протокол заседания Наблюдательного совета ведется секретарем Наблюдательного совета.

Мнение члена Наблюдательного совета, голосовавшего против принятого решения, по его требованию заносится в протокол заседания Наблюдательного совета.

К протоколу заочного голосования прилагаются письменные мнения членов Наблюдательного совета.

4.3. Протокол заседания (заочного голосования) Наблюдательного совета составляется не позднее пяти дней с даты проведения заседания (с даты, до которой принимались документы, содержащие сведения о заочном голосовании членов Наблюдательного совета).

4.4. В протоколе заседания (заочного голосования) Наблюдательного совета указываются:

дата, время и место проведения заседания, а в случае заочного голосования – дата, до которой принимались документы, содержащие сведения о голосовании членов Наблюдательного совета, и способ отправки этих документов;

сведения о лицах, принявших участие в заседании, и (или) о лицах, направивших документы, содержащие сведения о голосовании;

повестка дня;

результаты голосования по каждому вопросу повестки дня;

сведения о лицах, проводивших подсчет голосов, если подсчет голосов был поручен определенным лицам;

сведения о лицах, голосовавших против принятия решения Наблюдательного совета и потребовавших внести запись об этом в протокол;

сведения о ходе проведения заседания или о ходе голосования, если член Наблюдательного совета требует их внести в протокол;

сведения о лицах, подписавших протокол;

принятые решения.

4.5. Хранение оригиналов протоколов заседаний (заочного голосования) Наблюдательного совета обеспечивает секретарь Наблюдательного совета. Протоколы нумеруются в хронологическом порядке, формируются в отдельное дело и являются документами, содержащими информацию ограниченного доступа.

4.6. Секретарь Наблюдательного совета подготавливает и рассылает выписки из протоколов заседаний (заочного голосования) Наблюдательного совета представителям Центра, реализующим выполнение соответствующих решений Наблюдательного совета.

Приложение № 2
к Указу Раиса
Республики Татарстан
от «10» ноября 2023 года
№ 775

**Состав**
**Наблюдательного совета научно-образовательного центра мирового уровня в Республике Татарстан**

| | |
|---|---|
| Минниханов Рустам Нургалиевич | Раис Республики Татарстан, председатель Наблюдательного совета |
| Фазлеева Лейла Ринатовна | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан, заместитель председателя Наблюдательного совета |
| Минниханов Рифкат Нургалиевич | президент государственного научного бюджетного учреждения «Академия наук Республики Татарстан», заместитель председателя Наблюдательного совета (по согласованию) |
| Яруллин Рафинат Саматович | генеральный директор акционерного общества «Татнефтехиминвест-холдинг», заместитель председателя Наблюдательного совета (по согласованию) |
| Гатиятов Айрат Ринатович | заместитель Министра науки и высшего образования Российской Федерации (по согласованию) |
| Гильмутдинов Альберт Харисович | помощник Раиса Республики Татарстан |
| Зяббаров Марат Азатович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан |
| Каримов Альберт Анварович | заместитель Министра промышленности и торговли Российской Федерации (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Коробченко Олег Владимирович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр промышленности и торговли Республики Татарстан |
| Миннуллин Марсель Мансурович | министр здравоохранения Республики Татарстан |
| Сорокин Валерий Юрьевич | генеральный директор акционерного общества «Связьинвестнефтехим» (по согласованию) |
| Хадиуллин Ильсур Гараевич | министр образования и науки Республики Татарстан |
| Хайруллин Айрат Ринатович | министр цифрового развития государственного управления, информационных технологий и связи Республики Татарстан |
| Шагиахметов Мидхат Рафкатович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр экономики Республики Татарстан |
| Шайхутдинов Роман Александрович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан |

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәге турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәге турында» 2020 елның 24 февралендәге ПУ-115 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2020 елның 21 июлендәге ПУ-431 номерлы һәм 2020 елның 14 ноябрендәге ПУ-755 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктта «федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф оешмаларының» сүзләрен «югары белем бирү мәгариф программалары һәм өстәмә һөнәри программалар буенча мәгариф эшчәнлеге алып баручы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3, 6 һәм 7 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

в) 1 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

г) Татарстан Республикасында дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәге күзәтчелек советы турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

д) Татарстан Республикасында дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәге күзәтчелек советы составын 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 10 ноябрь
№ 775

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «10» ноябрендәге
775 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасында дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәгенең күзәтчелек советы турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасында дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәгенең күзәтчелек советы (алга таба – Күзәтчелек советы) Татарстан Республикасында дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәге (алга таба – Үзәк) белән идарә итүнең коллегиаль киңәшмә органы булып тора.

1.2. Күзәтчелек советы Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 30 апрелендәге 537 номерлы карары белән расланган Дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәкләренә югары белем бирү оешмаларының һәм фәнни үзәкләрнең икътисадның реаль секторында эшчәнлек алып баручы оешмалар белән катнашуы һәм берләшүе нигезендә федераль бюджеттан субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтүгә грантлар бирү кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр), Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эшчәнлек алып бара.

1.3. Күзәтчелек советы турындагы нигезләмә һәм Күзәтчелек советының составы Татарстан Республикасы Рәисе Указы нигезендә раслана.

2. Күзәтчелек советының төп бурычлары, функцияләре һәм хокуклары

2.1. Үзәк эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыру һәм аның эшчәнлеге программасын билгеләү Күзәтчелек советының төп бурычлары булып тора.

2.2. Күзәтчелек советы үзенә йөкләнгән төп бурычларны хәл итү өчен түбәндәге функцияләрне башкара:

Үзәк эшчәнлеге программасын раслау;

Үзәк эшчәнлеге программасына һәм Үзәктә катнашучылар составына үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәрне килештерү;

Кагыйдәләрнең 24 пунктында каралган очракларда, Россия Федерациясе Фән һәм югары белем бирү министрлыгы белән килештереп, ә кайбер башка очракларда дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәкләре Советы белән килештереп, Үзәк эшчәнлеге программасына һәм Үзәктә катнашучылар составына үзгәрешләр кертү (кирәк булганда);

Үзәк эшчәнлеге программасын үтәүгә еллык мониторинг һәм Үзәк эшчәнлеге программасын үтәү нәтиҗәләре турында еллык хисапны раслау;

Үзәкнең Идарә советы турында нигезләмәне һәм аның составын раслау, Үзәкнең башка консультатив һәм киңәшмә органнарын формалаштыру тәртибен, аларның бурычларын һәм функцияләрен билгеләү;

Үзәк эшчәнлеге программасында һәм Кагыйдәләрдә каралган башка функцияләр.

2.3. Үзенә йөкләнгән төп бурычлар һәм функцияләрне үтәү өчен Күзәтчелек советы түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, федераль дәүләт хакимият органнарының территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан Күзәтчелек советы вәкаләтләренә караган мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары һәм оешмалар вәкилләрен чакырырга һәм Күзәтчелек советы вәкаләтләренә караган мәсьәләләр буенча аларның аңлатмаларын тыңларга;

федераль дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясенең башка субъектлары муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары һәм оешмалар белән хезмәттәшлек итәргә;

Күзәтчелек советының эшчәнлегендә катнашу өчен фәнни хезмәткәрләр, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары, бизнес-берлек вәкилләрен, шулай ук иҗтимагый һәм сәяси эшлеклеләрне җәлеп итәргә.

## 3. Күзәтчелек советы эшчәнлеген оештыру

3.1. Күзәтчелек советы составы федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары, югары белем бирү мәгариф программалары һәм өстәмә һөнәри программалар буенча мәгариф эшчәнлеге алып баручы оешмалар, фәнни оешмалар һәм икътисадның реаль секторында эшчәнлек алып баручы оешмалар вәкилләреннән төзелә.

3.2. Күзәтчелек советы составына үз эшчәнлеген җәмәгать башлангычларда алып баручы Күзәтчелек советы рәисе, Күзәтчелек советы рәисе урынбасарлары һәм Күзәтчелек советы әгъзалары керә.

3.3. Күзәтчелек советын Күзәтчелек советы рәисе – Татарстан Республикасы Рәисе җитәкли.

3.4. Күзәтчелек советы үз карары нигезендә Күзәтчелек советы секретарен билгеләп куя.

3.5. Күзәтчелек советының эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе тарафыннан башкарыла.

3.6. Күзәтчелек советы утырышлары Күзәтчелек советы рәисе кушуы буенча Күзәтчелек советы секретаре тарафыннан чакырыла. Күзәтчелек советы утырышлары, кирәк булган саен, әмма кимендә елына бер тапкыр уздырыла.

3.7. Күзәтчелек советы утырышлары турыдан-туры һәм читтән торып катнашу формасында үткәрелә. Күзәтчелек советы утырышы видео-конференц-элемтә системасын кулланып үткәрелергә мөмкин.

3.8. Күзәтчелек советы утырышы, әгәр анда Күзәтчелек советы әгъзаларының гомуми санынннан ким дигәндә өчтән икесе катнашса, гамәлгә хокуклы дип санала.

3.9. Күзәтчелек советы утырышының көн тәртибе Күзәтчелек советы әгъзалары тәкъдимнәре нигезендә формалаштырыла.

3.10. Күзәтчелек советы секретаре Күзәтчелек советы утырышын үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Күзәтчелек советы рәисенә Күзәтчелек советы утырышының көн тәртибе проектын, утырышның көн тәртибе мәсьәләләре буенча документларны һәм мәгълүмати материалларны бирә.

3.11. Күзәтчелек советы утырышының Күзәтчелек советы рәисе тарафыннан расланган көн тәртибе, шулай ук утырышның көн тәртибе мәсьәләләре буенча документлар һәм мәгълүмати материаллар, утырышны уздыру көненә кадәр биш көннән дә соңга калмыйча, Күзәтчелек советының башка әгъзаларына җибәрелә.

3.12. Күзәтчелек советы утырышларында чакырылган экспертлар, шулай ук Үзәкнең Идарә советы әгъзалары киңәшләшү рәвешендә тавыш бирү хокукы белән катнаша.

3.13. Күзәтчелек советы утырышында карарлар ачык тавыш бирү юлы белән, әлеге утырышта катнашучы әгъзаларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта, Күзәтчелек советы рәисе тавышы хәлиткеч була.

3.14. Күзәтчелек советы карары Күзәтчелек советы әгъзаларыннан язма рәвештә сораштыру уздыру юлы белән читтән торып тавыш бирү аша кабул ителергә мөмкин.

Тавыш бирүгә куелган мәсьәлә буенча материаллар теркәлгән читтән торып тавыш бирү уздыру турындагы хәбәр, читтән торып тавыш бирү йомгаклары ясалганга кадәр биш көн кала, Күзәтчелек советы секретаре тарафыннан Күзәтчелек советы әгъзаларына аның алынуын тәэмин итә торган теләсә нинди ысул белән (шул исәптән почта, факсимиле элемтәсе һәм электрон почта аша да) юллана. Хәбәрдә карап тикшерелә торган мәсьәлә буенча Күзәтчелек советы әгъзасы тарафыннан үз фикерен язма рәвештә бирү вакыты тәмамлану датасы күрсәтелә.

Күзәтчелек советы әгъзаларының язма рәвештә бирелгән фикерләрен гомумиләштерү һәм читтән торып тавыш бирүгә йомгак ясауны Күзәтчелек

советы секретаре башкара.

Күзәтчелек советы карары, әгәр Күзәтчелек советы әгъзаларының гомуми санының ким дигәндә өчтән икесе билгеләнгән вакытта язма рәвештә үз фикерен белдерсә, кабул ителгән дип санала.

Карар Күзәтчелек советының язма рәвештә үз фикерен белдергән әгъзалары гомуми санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта, Күзәтчелек советы рәисенең тавышы хәлиткеч була.

## 4. Күзәтчелек советы карарларын рәсмиләштерү тәртибе

4.1. Күзәтчелек советының утырышында яисә читтән торып тавыш бирү йомгаклары буенча кабул ителгән карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа Күзәтчелек советы рәисе кул куя.

4.2. Күзәтчелек советы утырышы беркетмәсе Күзәтчелек советы секретаре тарафыннан алып барыла.

Күзәтчелек советының кабул ителгән карарга каршы тавыш биргән әгъзасының фикере аның таләбе буенча Күзәтчелек советы утырышы беркетмәсенә кертелә.

Читтән торып тавыш бирү беркетмәсенә Күзәтчелек советы әгъзаларының язма рәвештә бирелгән фикерләре теркәлә.

4.3. Күзәтчелек советы утырышы (читтән торып тавыш бирү) беркетмәсе утырыш үткәрелгән көннән биш көннән дә соңга калмыйча (Күзәтчелек советы әгъзаларының читтән торып тавыш бирүе турында мәгълүматлар күрсәтелгән документлар кабул ителүнең соңгы көне датасыннан) төзелә.

4.4. Күзәтчелек советы утырышы (читтән торып тавыш бирү) беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

утырышны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны, читтән торып тавыш бирү очракларында – Күзәтчелек советы әгъзаларының тавыш бирүе турындагы мәгълүматлар күрсәтелгән документлар кабул ителүнең соңгы көне датасы һәм бу документларны юллау ысулы;

утырышта катнашкан затлар һәм (яисә) тавыш бирү турында мәгълүматлар күрсәтелгән документларны юллаган затлар турында мәгълүматлар;

көн тәртибе;

көн тәртибе мәсьәләләренең һәрберсе буенча тавыш бирү нәтиҗәләре;

әгәр тавышларны санау билгеле бер затларга йөкләнгән булса, тавышларны санауны башкарган затлар турында мәгълүматлар;

Күзәтчелек советы карарын кабул итүгә каршы тавыш биргән һәм бу турыда язманы беркетмәгә кертүне таләп иткән затлар турында мәгълүматлар;

әгәр Күзәтчелек советы әгъзасы аларны беркетмәгә теркәүне таләп итсә, утырышны уздыруның барышы яисә тавыш бирү барышы турында мәгълүматлар;

беркетмәгә кул куйган затлар турында мәгълүматлар;

кабул ителгән карарлар.

4.5. Күзәтчелек советы утырышлары (читтән торып тавыш бирү) беркетмәләренең төп нөсхәләре саклanышын Күзәтчелек советы секретаре тәэмин итә. Беркетмәләргә хронологик тәртиптә номер сугыла, алар аерым эш тупланмасы рәвешендә формалаштырыла һәм кулланылышы чикләнгән мәгълүматлы документлар булып тора.

4.6. Күзәтчелек советы секретаре Күзәтчелек советы утырышлары (читтән торып тавыш бирү) беркетмәләреннән өземтәләр әзерли һәм аларны Күзәтчелек советының тиешле карарлары үтәлешен тормышка ашыручы Үзәк вәкилләренә җибәрә.

---

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «10» ноябрендәге
775 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасында дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-мәгариф үзәгенең күзәтчелек советы составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Рәисе, Күзәтчелек советы рәисе |
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Күзәтчелек советы рәисе урынбасары |
| Миңнеханов Рифкать Нургали улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе президенты, Күзәтчелек советы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Яруллин Рафинат Самат улы | «Татнефтехиминвест-холдинг» акционер җәмгыяте генераль директоры, Күзәтчелек советы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Гатиятов Айрат Ринат улы | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министры урынбасары (килешү буенча) |
| Гыйльметдинов Альберт Харис улы | Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе |
| Җәббаров Марат Азат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Коробченко Олег Владимирович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Миңнуллин Марсель Мансур улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Сорокин Валерий Юрьевич | «Связьинвестнефтехим» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәйруллин Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |
| Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Шәйхетдинов Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |

______________